Шәһәр күләмендә география фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың йомгаклау этабы биремнәре
2024-2025 уку елы
9 нчы сыйныф

Эш вакыты – 120 минут
Гомуми балл – 94

1. **Төньяк диңгез юлы кайчан ачыла? Ул кайдан башлана, кайда төгәлләнә, озынлыгы ничә километр? (6 балл)**

   _____
   _____

2. **Саналып киткән шәһәрләрнең кайсы Төньяк поляр түгәрәк аръягында урнашкан? (2 балл)**
   Шәһәрләр: Петропавловск-Камчатка, Анадырь, Архангельск, Якутск, Тикси, Иркутск, Ханты-Мансийск.
   _____

3. **Санап киткәннәрнең кайсы графит чыганагы булып тора һәм ул кайда урнашкан? (2 балл)**
   Михайлов, Тихвин, Курейск, Райчихин, Самотлор, Сеймчан.
   _____

4. **“Төньяк балкышы” (“Сияние Севера”) нәрсә ул? Атмосфера күренеше белән бутамаска. (2 балл)**

   а) Атом бозваткычы аталышы
   б) Газүткәргеч магистраль
   в) Дөньяда иң зур алмаз
   г) Танылган ненец фольклор ансамбле
   д) Яңа төр яктырту җиһазы

5. **Хаталы парны табыгыз. Дөрес итеп языгыз. (2 балл)**

   а) Рефтин ГРЭСы – Свердловск өлкәсендә
   б) Усть-Илим ГЭСы – Хакасиядә
   в) Билибин АЭСы – Чукотка автономияле өлкәсендә
   г) Рыбинск ГЭСы – Ярославль өлкәсендә

6. **Россиянең кайсы шәһәрендә домна миче кулланмый гына чуен коела? (4 балл)**
   _____
   _____
   _____
   _____

7. **Россиянең Азия өлешендә халык тыгызлыгы кайсы юнәлештә үсә бара? (2 балл)**

а) Төньяктан көньякка таба
б) Көньяктан төньякка таба
в) Көнбатыштан көнчыгышка таба

8. **Авыл хуҗалыгы чималыннан азык-төлек, киң куллану товарлары җитештерү һәм халыкны тәэмин итү белән бәйле икътисадый (экономик) тармак ничек атала? (2 балл)**

а) Агробизнес
б) Агросәнәгать комплексы
в) Аграр өлкә
г) Аграр мәсьәлә

9. **Россиядә машина төзелеше тармагы ил буенча таралган. Урал, Үзәк Россия һәм Идел буенда алар аеруча күп. Моның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз? (6 балл)**

_____
_____
_____
_____

10. **Россиянең Себер территориясе ягулык-энергетика ресурларына бик бай. Киресенчә, илнең Европа өлешендә энергияне куллану ихтыяҗы аеруча зур. Бу проблеманы уңай хәл итү өчен сездә нинди тәкъдимнәр бар? Һәр җавапка ике балл, тулы җавапка (8 балл)**

_____
_____
_____
_____
_____

11. **АПК (агросәнәгать комлексының) звеноларын һәм тармак составын туры китереп, уклар ярдәмендә күрсәтегез. (2 балл)**

а) АПКны тәмин итүче тармаклар	1. Авыл хуҗалыгы машиналары җитештерү
б)Авыл хуҗалыгы	2.Җиңел һәм азык-төлек сәнәгате
	3. Терлекчелек һәм үсемлекчелек

12. **Гидроэлектростанция урнашкан Идел буе районына кермәгән шәһәр исемен билгеләгез. (2 балл)**

а) Идел буе (Волжская)
б) Балаков
в) Волгоград
г) Саратов

13. Санап кителгән чималларның кайсы җитештерүдә зур әһәмияткә ия, шуны билгеләгез. (2 балл)

а) калий ашламалары
б) күкерт кислотасы
в) пластмасса
г) селтеләр

14. Үз хаҗәтләрен канәгатьләндерү өчен генә азык-толек җитештерүче хуҗалык тибы ничек атала? (4 балл)

_____

_____

15. Ерак Көнчыгыш икътисадый районы кайсы ягы белән башка районнардан аерылып тора? (2 балл)

а) автономияле округ
б) автономияле өлкә
в) республика
г) край

16. Россиядәге ташкүмер бассейннарын күмер чыгару буенча кимүгә таба бару тәртибендә урнаштырып языгыз: (4 балл)

а) Печора б) Кузбасс в) Канск-Ачинск г) Көньяк Якутия

_____

17. Бер предприятиенең продукциясе икенче предприятиенең чималы яки полуфабрикаты булып хезмәт итүче чиктәш өлкәләрнең промышленность предприятиеләре берләшмәсе ничек атала? (4 балл)

_____

18. Үзәк металлургия базасы булган Череповец шәһәре янында руда запаслары һәм кокслана торган күмер юк. Шулай булуга карамастан, биредә тулы циклда эшли торган эре металлургия комбинаты бар. Аны ни өчен шунда төзегәннәр? (10 балл)

_____

_____

_____

_____

_____

_____

19. Контурлы картада тракторлар ясау үзәкләрен шартлы билге – пунсоннар белән күрсәтегез. (16 балл)



20. Әлеге шәһәрне төрки телдә “яңа авыл” дип атыйлар. Аңа 1730 нчы елда ук нигез салына, һәм ул 1771 нче елдан шәһәр булып санала. Ул Себердәге бер якның үзәк шәһәре. Халык саны 500 меңнән артык. Ул зур бер елга буендагы мәдәни үзәкләрнең берсе булып тора. Бу шәһәрдә А.С. Пушкин һәм В.М. Шукшин һәйкәлләре бар. Шәһәрдә машина ясау заводлары эшли. Двигательләр, җылыту мичләре, механик пресслар, транспорт машиналары җитештерелә. Химия, киҗе-мамык тукымалары җитештерү тармаклары да үскән. Азык-төлек тә җитештерелә.

Бу край үзәге ничек атала һәм ул нинди елга буенда урнашкан? (4 балл)

_____

_____

21. Ерак Көнчыгыш халык тыгызлыгы ягыннан соңгы урында тора. Биредә табигый ресурслар җитәрлек. Ул халык тыгыз булган илләр белән чиктәш. Шулай булуга карамастан, халык тыгызлыгы ни өчен бик аз? Нигә табигый ресурслар начар үзләштерелә һәм шул сәбәпле аның экономик үсеше дә түбән? (6 балл)

_____

_____

_____

_____

_____

22. Кара туфраклы үзәк районның авыл хуҗалыгы специальләшү (махсуслашу) тармагына карамаган җавапны билгеләгез: (2 балл)

а) Көнбагыш үстерү

б) Бөртеклеләрне игү

в) Сарык асрау

г) Чөгендер үстерү